СОВЕТ КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.06.2023 с. Куралово 33-197

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, яки варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яки барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. «Урындагы салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 28-159 номерлы Куралово авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Совет рәисе,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы Р.Е.Тарасов